Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге составына керүче
Күгәрчен авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

19 ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 19 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге составына керүче Күгәрчен, Зәнгәр-Күл авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, беренче группа инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз яшәүче пенсионерлардан, мобилизацияләнгән грагражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, (гомуми саны 30 проценттан артмаган очракта) һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы»:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су белән тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 545 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 277 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 277 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге составына керүче Күгәрчен авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: "«Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге составына керүче Күгәрчен, Зәнгәр-Күл авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, беренче группа инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз яшәүче пенсионерлардан, мобилизацияләнгән халкы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, (гомуми саны 30 процентган артмаган очракта) һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы»:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су белән тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күгәрчен авылы, Зәитовлар урамы, 1А йорт Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы: А.Т.Сафин